**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен командировкага җибәрү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында**

Россия Федерациясе Президентының «Федераль дәүләт граждан хезмәткәрләрен командировкага җибәрүнең Россия Федерациясе Президентының 2005 елның 18 июлендәге 813 номерлы Указы белән расланган тәртибе һәм шартларына үзгәреш кертү турында» 2015 елның 30 сентябрендәге 492 номерлы Указы чыгуга бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен командировкага җибәрү тәртибе һәм шартлары турында» 2005 елның 9 сентябрендәге ПУ-366 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2008 елның 11 гыйнварындагы ПУ-3 номерлы, 2010 елның 12 июлендәге ПУ-445 номерлы, 2010 елның 14 октябрендәге ПУ-695 номерлы, 2010 елның 17 ноябрендәге ПУ-751 номерлы, 2011 елның 14 февралендәге ПУ-57 номерлы, 2011 елның 5 октябрендәге ПУ-627 номерлы, 2013 елның 18 гыйнварындагы ПУ-31 номерлы, 2013 елның 12 февралендәге ПУ-108 номерлы һәм 2015 елның 25 февралендәге ПУ-189 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен командировкага җибәрү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәгә, аңа түбәндәге эчтәлекле $21^2$ пункты өстәп, үзгәреш кертергә:

«$21^2$. Граждан хезмәткәренең командировкага җибәрелү урынына кадәр һәм (яисә) кире – Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтен даими узу урынына кайту өчен – һава транспорты файдаланылганда транспортта йөрү документлары (билетлар) бары Россия авиакомпанияләре яисә башка дәүләтләр – Евразия икътисадый берлеге әгъзалары авиакомпанияләре рейсларына, әлеге авиакомпанияләр граждан хезмәткәре командировкага җибәрелгән урынга пассажирлар йөртүне башкармаса яки әлеге авиакомпанияләр рейсларына граждан хезмәткәре командировкасының башыннан ахырына кадәр транспортта йөрү документларын (билетларны)

рәсмиләштерү (сатып алу) аларның булмавы сәбәпле мөмкин булмау очрагыннан тыш, рәсмиләштерелә (сатып алына).».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2015 ел, 19 октябрь
№ ПУ-998